БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-54-26, факс: (84368) 2-51-34. E-mail: Baltasi.Rayispolkom@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

«07» 10. 2024 № 01-35/3094

**«Капиталь төзелеш объектыннан яисә җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү» проекты буенча гавами тыңлаулар башлану хакында хәбәр итү**

**1.** «Капиталь төзелеш объектыннан яисә җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү» проекты буенча **гавами тыңлаулар башлану хакында хәбәр итәбез**(алга таба - проект).

**2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**

- «Капиталь төзелеш объектыннан яисә җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү» проекты.

**3. Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:**

Проект буенча гавами тыңлаулар 2024 елның 07 октябреннән 2024 елның 11 октябренә кадәр чорда уздырыла. Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:

- гавами тыңлауларның башлануы турында хәбәр итү;
- гавами тыңлаулар уздыру турындагы хәбәрне җибәрү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**4. Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:**

Проект буенча гавами тыңлауларда катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:

- Перфилов Юрий Михайлович - Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы, кадастр номерлары 16:12:130101:1, 16:12:130502:98 булган җир кишәрлегенең хокук иясе;
- Грахов Константин Викторович - «О.Н.Исаев исемендәге Урта Көшкәт урта мәктәбе» МББУ директоры, кадастр номерлары 16:12:130101:122, 16:12:130101:128 булган участокка хокукы булган вәкаләтле зат;

- Семенова Нина Николаевна - кадастр номеры 16:12:130502:101 булган участокның хокук иясе;

- Апаков Сергей Пантелеймонович - кадастр номеры 16:12:130502:100 булган участокның хокук иясе;

- Терентьев Василий Васильевич - кадастр номеры 16:12:130502:103 булган кишәрлекнең хокук иясе;

- Павлова Екатерина Витальевна - кадастр номеры 16:12:130502:104 булган җир кишәрлегенең хокук иясе.

**5. Гавами тыңлаулар үткәрелә торган территория:**

Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона (ОД 4-2)

**6. Проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:**

- Татарстан Республикасы, Балтач районы, Урта Көшкәт ав., Үзәк ур., 6 йорт адресы буенча урнашкан Урта Көшкәт авыл клубы бинасы - 2024 елның 09 октябре;

**7. Проект экспозицияләрен үткәрү сроклары:**

2024 елның 09 октябреннән алып - 2024 елның 11 октябренә кадәрге чорда.

**8. Экспозицияләрне карау мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:** эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, төшке ашка тәнәфес - 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

**9. Гавами тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы түбәндәге искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:**

2024 елның 09 октябреннән алып 2024 елның 11октябренә кадәрге чорда Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $5^1$ статьясының 12 өлеше (алга таба - РФ ГрК) нигезендә узган гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне түбәндәгечә кертергә хокуклы:

- рәсми сайт ярдәмендә;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гавами тыңлауларны оештыручы адресына язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә: 422250, Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтач шәһәр тибындагы поселогы, Ленин урамы, 42 йорт, тел. (84368) 2-51-34 (9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр);

- гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен исәп китабында (журналда) язу юлы белән түбәндәге адрес буенча: 422242, Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авылы, Үзәк ур., 6 йорт (8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр).

РФ ГрК ның $5^1$ статьясының 12 өлеше нигезендә идентификацияләнгән гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздыру барышында язма яки телдән рәвештә тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү хокукына ия.

**10. Гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

Проект буенча гавами тыңлауларны 2024 елның 11 октябрендә 9.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Балтач районы, Урта Көшкәт ав., Үзәк ур., 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан Урта Көшкәт авыл клубы бинасында уздырырга.

**11. Проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:**

Проект Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) 2024 елның 09 октябреннән «Район турында > Поселение > Урта Көшкәт авыл җирлеге > Мәгълүмат материаллары (https://baltasi.tatarstan.ru/vesti_kushket.htm) вкладкасында урнаштырылачак.

**12. Әлеге хәбәр итүне** Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru).

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов